| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2018 Казан ш. № 6-220/тп

2019 елга "Минзәлә районы коммуналь челтәрләре" акционер җәмгыятенең ташландык суны чыгару үзәкләштерелгән системасына кушуга(технологик тоташтыруга) тарифлар билгеләү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, "Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы карарлары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Су белән тәэмин итү һәм (яки) ташландык суны чыгару үзәкләштерелгән системаларына кушкан (технологик тоташтырган) өчен түләү индивидуаль тәртиптә билгеләнә торган очракта гариза бирүчеләр объектларының кушыла (тоташтырыла) торган йөкләнеше зурлыгын билгеләү турында" 2017 елның 22 апрелендәге 239 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. "Минзәлә районы коммуналь челтәрләре" акционер җәмгыятенең ташландык суны чыгару үзәкләштерелгән системасына кушуга (технологик тоташтыруга) тарифларны әлеге карарга кушымтада каралганча билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
2018 елның 21 ноябрендәге 6-220/тп
номерлы карарына кушымта

"Минзәлә районы коммуналь челтәрләре" акционер җәмгыятенең ташландык суны чыгару үзәкләштерелгән системасына кушуга (технологик тоташтыруга) тарифлар

| т/б № | Күрсәткеч исеме | Исәпләү берәмлеге | Тоташтыруга тарифлар (НДСны исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Тоташтырыла торган йөкләнешкә тарифның төп ставкасы | мең сум/ тәүлегенә куб.метр | 1,2008 |
| 2. | Челтәрләр озынлыгына тарифның төп ставкасы | мең сум/ км | 3 785,05 |
| 3. | Челтәрләрнең диаметрына карап, тарифны дифференциацияләү коэффициенты | | |
| 3.1. | диаметры 40 мм һәм аннан да кимрәк | - | - |
| 3.2. | диаметры 40 мм күбрәк һәм 70 мм кадәр (аны кертеп) | - | - |
| 3.3. | диаметры 70 мм күбрәк һәм 100 мм кадәр (аны кертеп) | - | - |
| 3.4. | диаметры 100 мм күбрәк һәм 150 мм кадәр (аны кертеп) | - | 0,51 |
| 3.5. | диаметры 150 мм күбрәк һәм 200 мм кадәр (аны кертеп) | - | 0,51 |
| 3.6. | диаметры 200 мм күбрәк һәм 250 мм кадәр (аны кертеп) | - | - |
| 3.7. | диаметры 250 мм күбрәк һәм аннан да зуррак | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге